**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«16» октябрь 2019 ел** **№ 300**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының29.12.2018 ел №381 «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары турында карарына үзгәрешләр кертү турында

19.07.2018 ел № 204-ФЗ «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны үтәү йөзеннән, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, №210 Федераль закон нигезендә, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 01.12.2014 ел, №419 - ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә урнаштыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 30.12.2017 ел №1716 карары нигезендә, карар чыгара:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының29.12.2018 ел №381 «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары турында карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. №3, №4, №6, №7, №11, №13, №16, № 17, № 18 кушымталарда:

- 2.14.пунктның «Стандартка таләпләрнең эчтәлеге» графасында икенче абзацта «муниципаль районның,» сүзләреннән соң, «яисә КФҮ аша: 423330, ТР, Азнакай ш., м. Солтангалиев ур., 24 йорт.» сүзләре белән тулыландырырга;

- 2.15. пунктның в графе «Стандартка таләпләрнең эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

"Күп функцияле үзәктә хезмәт күрсәтелми.»;

-3.2. пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарның опека һәм попечительлек бүлегенә яки КФҮкә консультация сорап мөрәҗәгать итүе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора. Опекун белгечкә паспорт, ә Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда аның шәхесен таныклаучы башка документ; опекун билгеләү һәм опекун билгеләү турында норматив хокукый акт (карар, боерык, карар һ.б.), яисә опекун таныклыгы күрсәтә.»;

- 3.2 пунктта икенче абзацта «опека һәм попечительлек бүлеге белгече» сүзләреннән соң «яисә КФҮ хезмәткәре» сүзләрен өстәргә»;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов